РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район, д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы, Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

07.02.2018 — № 5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Арташ авыл җирлеге Советы тарафыннан
2006 нчы елның 28 нче ноябрендә кабул ителгән
19 нчы номерлы «Арташ авыл җирлегендә халык
алдында тыңлаулар турында нигезләмәне раслау хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 31 гыйнварыннан 02-08-02-3-2018 номерлы Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба районы Арташ авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2006 нчы елның 28 нче ноябрендә кабул ителгән 19 нчы номерлы Арташ авыл җирлеге Советы карары белән расланган Арташ авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар турында нигезләмәнең 3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык алдында тыңлауларга:

- муниципаль берәмлекнең устав проекты, шулай ук әлеге уставны Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) законнары яки Россия Федерациясе субъекты законнарына туры китерү максатыннан төгәл күчереп язу формасыннан тыш уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты;

- җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;
- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;
- гамәлдәге законнар нигезендә тавыш бирү тәртибендә яки җыенда халыктан рөхсәт алу таләп итә торган сораулардан тыш, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору сораулары чыгарыла.

Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияне төзекләндерү проектлары, әлеге расланган документларга үзгәреш кертү проектлары, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән куллану төрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә үзгәртү карары проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары чикләреннән тайпылышка рөхсәт бирү карары проектлары, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү, расланган җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре булмаган очракта җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының бер рөхсәт ителгән куллану төреннән икенче рөхсәт ителгән куллану төренә үзгәртү буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар һәм аерым муниципаль норматив-хокукый актлар исәпкә алып, халык алдында тыңлаулар үткәрелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга.

Арташ авыл җирлеге башлыгы А. Р. Аглямзянов